**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАМСКО-УСТЬИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАМА ТАМАГЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

ул. Калинина, д.31,
пгт. Камское Устье, 422820

Калинин урамы, 31 йорт,
штп. Кама Тамагы, 422820

тел.: (884377) 2-18-85, факс: 2-20-70, e-mail: Kamuste.Ispolkom@tatar.ru, http://kamskoye-ustye.tatarstan.ru.

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

05.02.2021 № 93

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитетының «Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» 2016 елның 24 июнендәге 424 номерлы карары белән расланган гражданнар милкенә муниципаль торак фондының торак урыннарын тапшырганда документлар рәсмиләштерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында (2018 елның 3 маендагы 372 номерлы редакциясендә)

Муниципаль норматив-хокукый актларны гамәлдәге законнарга туры китерү сәбәпле, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитетының «Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында»2016 елның 24 июнендәге 424 номерлы карары (2018 елның 03 маендагы 372 номерлы редакциясендә) белән расланган гражданнар милкенә муниципаль торак фондының торак урыннарын тапшырганда документлар рәсмиләштерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.5 пунктта «5» пунктчасында Йорт китабыннан өземтә (документ коммерция оешмалары тарафыннан бирелгән очракта);» төшереп калдырырга;

2.6 пунктта «Йорт китабыннан өземтә (әгәр документ җирле үзидарә органнары тарафыннан бирелгән очракта)» сүзләрен «Яшәү урыны буенча теркәлү турында белешмәләр - Россия Эчке эшләр министрлыгы» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле пунктчалар өстәргә:

«4) Гариза бирүче гаиләсенең 14 яшькә җитмәгән барлык әгъзалары өчен туу турында таныклык - граждан хәле актларын теркәү органнары;

5) Мөрәҗәгать итүче һәм/яисә аның гаилә әгъзалары өчен никахны теркәү турындагы таныклык - граждан хәле актларын теркәү органнары;

6) Ата булуны билгеләү турында таныклык - граждан хәле актларын теркәү органнары;

7) Никахны өзү турында таныклык - граждан хәле актларын теркәү органнары;

8) Опека билгеләү турында белешмәләр - Россия Федерациясе Пенсия фонды.»;

3.4.1пунктта «йорт кенәгәсеннән күчермәләр» сүзләрен «яшәү урыны буенча теркәлү турында белешмәләр» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле пунктчалар өстәргә:

«4) бала туу турында таныклык;

5) никахлашу турында таныклык;

6) ата булуны билгеләү турында таныклык;

7) никахны өзү турында таныклык;

8) опека билгеләү турында белешмәләр».

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад мәсьәләләре буенча урынбасары М.Х. Хабибулловага йөкләргә

Җитәкче Р.М. Заһидуллин